РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.07.2025 № 139-п

Әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясауны бәяләү материалларын да кертеп, «ФУРАН җайланмаларында калдыкларны утильләштерү технологиясе " дәүләт экология экспертизасы объекты (техник документация проекты) буенча җәмәгать тыңлаулары рәвешендә иҗтимагый фикер алышуны билгеләү турында

«Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүне уздыру тәртибе турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 28 ноябрендәге 1644 номерлы карары белән расланган әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясауны бәяләүне уздыру кагыйдәләренә ярашлы рәвештә, 1995 елның 23 ноябрендәге «Экологик экспертиза турында» 174-ФЗ номерлы Федераль законның 9 нчы маддәсенә таянып, тормыш эшчәнлегенең уңай шартларына кеше хокукларын саклау максатларында һәм 2025 елның 16 июлендәге «МИАЛ» ҖЧҖ нең №15/25 номерлы мөрәҗәгате белән бәйле рәвештә

КАРАР ЧЫГАРАМ:

1. Дәүләт экология экспертизасы объекты (техник документация проекты) "ФУРАН җайланмаларында калдыкларны утильләштерү технологиясе", әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясауны бәяләү (алга таба – ОВОС) материалларын да кертеп, җәмәгать тыңлаулары рәвешендә иҗтимагый фикер алышуларын оештырырга.

2. Билгеләргә:

- Җәмәгать тыңлауларын үткәрү датасы һәм вакыты - 2025 елның 07 августы, Мәскәү вакыты белән 11.00 сәгатьтә.

- Үткәрү урыны - Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Байлар Сабасы ш.т.б., Г. Закиров урамы, 52 йорт, актлар залы.

3. Фикер алыша торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, шулай ук чыгыш хокукы белән иҗтимагый тыңлауларда катнашуга бирелергә мөмкин булган гаризалар түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 422060, Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Байлар Сабасы ш.т.б., Г.Закиров ур., 52 йорт, 8(84362) 2-31-33, 2-31-44, факс: 8(84362) 2-31-74, 8(84362)2-31-97, e-mail: saba@tatar.ru;

- Чыгыш ясау хокукы белән җәмәгать тыңлауларында катнашу очен гаризалар бирү срогы - 06.08.2025 елга кадәр.

4. Җәмәгать тыңлауларын үткәрүне Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләргә.

5. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетына:

- «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында җәмәгать тыңлауларын һәм иҗтимагый фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 20 апрелендәге 209 номерлы

Саба муниципаль районы Советы карары нигезендә җәмәгать тыңлауларын үткәрүне тәэмин итәргә;

- Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://saby.tatarstan.ru.
- 2025 елның 25 июленнән, 2025 елның 23 августына кадәрге чорда әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясауны бәяләү материалларын да кертеп, техник документация проекты материалларыннан файдалану мөмкинлеген оештырырга;
- «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында тиешле мәгълүмат урнаштыру һәм билгеләнгән процедураларны үткәрү юлы белән, шулай ук иҗтимагый фикер алышулар уздыру нәтиҗәләрен бастырып чыгару юлы белән иҗтимагый фикер алышулар уздыруны тәэмин итәргә;
- тыңлаулар уздыру регламентын билгеләргә;
- әлеге карар белән каралган срокларда иҗтимагый тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Саба муниципаль районы
Башлыгы Р.Н. Минниханов